ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__1727__ от «_28_»____12_______2016 г.

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2016 елның IV кварталына салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында

“Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 16 мартындагы ТРЗ- 13 санлы Татарстан Республикасы законы, Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмнәрен билгеләү методикасы, Россия Федерациясе төзелеш, архитектура һәм торак коммуналь хуҗалык минстрлыгының «2018 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы һәм 2016 елның IV кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метр уртача базар бәясе күрсәткечләре турында», 2016 елның 12 сентябрендәге №633/пр санлы боерыгы, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49,51 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә:**

1. 2016 елның IV кварталына социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда исәпкә алына торган керемнең максималь дәрәҗәсен 1 нче кушымта нигезендә түбәндәгечә билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы чиге:

1.1.1. ялгыз яшәүче гражданга: - 1 152 987 сум ;

1.1.2. ике кешелек гаиләгә - 1 467 438 сум;

1.1.3. өч кешелек гаиләгә – 1 886 706 сум;

1.1.4. дүрт кешелек гаиләгә - 2 515 608 сум;

1.1.5. биш кешелек гаиләгә - 3 144 510 сум;

1.1.6. алты кешелек гаиләгә - 3 773 412 сум;

1.1.7. җиде кешелек гаиләгә - 4 402 314 сум;

1.1.8. сигез кешелек гаиләгә - 5 031 216 сум.

1.2. гаилә әгъзасы яки ялгыз яшәүче граждан кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче гражданга – 19017,81 сум;

1.2.2. ике кешелек гаиләгә – 12102,25 сум;

1.2.3. өч яисә аннан күбрәк кешелек гаиләгә – 10431,32 сум.

2. Мамадыш муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары Р.К. Мөхәмәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче И. Э.Фаттахов

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма
комитетының
28.12.2016 ел, 1727 нче санлы карарына
Кушымта

# Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү МЕТОДИКАСЫ

1. Базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече

СЖ = НП*РС*РЦ, монда

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яисә мөлкәт бәясе чик күләме;

НП - бер әгъзага Торак урын бирү нормасы;

РС – гаиләдә кеше саны;

РЦ - РФ төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан 2016 елның IV кварталына расланган торак урынның гомуми мәйданының уртача исәп-хисап базар бәясе 1 кв. м.

| НП, кв. м | РС, чел. | РЦ за 1 кв. м, руб. | СЖ, руб. |
|---|---|---|---|
| 33 | 1 | 34939 | 1 152 987 |
| 42 | 2 | 34939 | 1 467 438 |
| 18 | 3 | 34939 | 1 886 706 |
| 18 | 4 | 34939 | 2 515 608 |
| 18 | 5 | 34939 | 3 144 510 |
| 18 | 6 | 34939 | 3 773 412 |
| 18 | 7 | 34939 | 4 402 314 |
| 18 | 8 | 34939 | 5 031 216 |

2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күрсәткече

ПД = 0,7*СЖ*ПС/(1-((1+ПС)-КП))/(0,25*РС), где

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күрсәткече;;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча Торак урын бирү нормасы буенча Торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

ПС - бер айга кредит буенча процент ставкасы (12,75/12=1,06);

КП - кредитның бөтен срогы өчен кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,25 - кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән нисбәте;

| Кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте | СЖ, руб. | ПС | КП, ай. | Кредит буенча түләүнең тулаем айлык керем белән нисбәте | РС, кеше | ПД, сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 0,7 | 1 152 987 | 1,06 | 180 | 0,25 | 1 | 19017,81 |
| 0,7 | 1 467 438 | 1,06 | 180 | 0,25 | 2 | 12102,25 |
| 0,7 | 1 886 706 | 1,06 | 180 | 0,25 | 3 | 10431,32 |

Башкарма комитет
җитәкчесе ярдәмчесе Р. К. Мухаметзянов